**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 5 февралендәге 255 номерлы карары**

## «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесен гамәлгә кую турында

Казан шәһәре Думасының 2011 елның 27 апрелендәге 14-5 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бүләкләре турында»гы карарының 8 номерлы кушымтаның 3 пункты нигезендә, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 6 октябрендәге 3004 номерлы «“2024 - 2028 елларга Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерү” муниципаль программасын раслау турында»гы карарын гамәлгә ашыру кысаларында, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшләүче затларны, шулай ук тармакны үстерүдә һәм популярлаштыруда актив катнашучы башка затларны Казан шәһәренең үсешенә һәм аның халкының иминлегенә ярдәм итүдәге аерым казанышлары өчен бүләкләү максатыннан карар **бирәм**:

1. «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесен гамәлгә куярга.

2. «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесе турында нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов):

3.1. «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесен һәм аның атрибутларын әзерләүне, исәпкә алуны һәм саклауны әлеге карарга кушымта нигезендә тәэмин итәргә;

3.2. «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесен әзерләүгә һәм тапшыруга бәйле

чыгымнарны Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетының бюджет исемлегендәге чаралары чикләрендә башкарырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 5 февралендәге
255 номерлы карары белән расланды

**«Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесе (алга таба – мактау билгесе) «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесенең (алга таба – Комитет) бүләкләү формасы, Россия Федерациясе гражданнарының Казан шәһәре территориясендә физик культураны, спортны, шул исәптән массакүләм спортны, югары казанышлар спортын үстерүгә, халыкны физик тәрбияләү системасын камилләштерүгә, оештыру-методика, укыту-тренировка эшчәнлеген камилләштерүгә зур шәхси өлеш кертүенең документ рәвешендәге таныклыгы булып тора.

1.2. Мактау билгесе белән дәүләт, муниципаль, иҗтимагый һәм хосусый учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре, спортчылар, спорт ветераннары, физик культура һәм спорт учреждениеләре коллективлары, Россия Федерациясе гражданнары нәтиҗәле хезмәтләре, Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүгә аерым өлеш керткән һөнәри эшчәнлектәге югары казанышлары өчен бүләкләнә.

Мактау билгесе белән бүләкләүгә кандидатлар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- физик культура һәм спорт тармагында кимендә ун ел эш стажы булу;
- бүләкләүгә тәкъдим итүче учреждение коллективында кимендә өч ел эш стажы булу.

1.3. Мактау билгесе белән бүләкләү турындагы үтенечнамә Казан шәһәре территориясендә эшчәнлек алып баручы дәүләт, муниципаль, иҗтимагый һәм хосусый учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләре (алга таба – инициатор) тарафыннан кузгатылырга мөмкин.

Мактау билгесе белән бүләкләү турында карар Мактау билгесе белән бүләкләнүгә тәкъдим итүләр нигезендә кабул ителә.

1.4. Мактау билгесе белән бүләкләү турындагы материаллар тапшыру планлаштырыла торган датага кадәр ике айдан да соңга калмыйча Комитет рәисе каравына тапшырыла.

Бүләкләү гражданнарның юбилей даталарына (50 яшь, 60 яшь һәм аннан соңгы һәр 10 ел), Физкультурачы көнен бәйрәм итүгә (августның 2 нче шимбәсе) һәм еллык эш йомгакларын ясауга туры китерелергә мөмкин.

Бүләкләүгә тәкъдим ителә торган затлар саны учреждениенең, оешманың эшләүче хезмәткәрләренең гомуми санынннан елына 5 проценттан артмаска тиеш.

1.5. Гражданнарны бүләкләүгә тәкъдим итү өчен түбәндәге документлар кирәк:

- әлеге нигезләмәнең 1 һәм 2 пунктлары нигезендә гражданинның конкрет казанышларын үз эченә алган характеристика) (1 номерлы кушымта);

- хезмәт коллективы җыелышы беркетмәсенең учреждение җитәкчесе, җыелыш секретаре тарафыннан имзалаган һәм мөһер белән расланган күчермәсе;

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (2 номерлы кушымта);

- бүләкләнүче затның Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе (2 нче, 3 нче битләр);

- учреждение, оешма уставының күчермәсе (1 - 3 нче битләр).

Тәкъдим итү кәгазе бүләкләүгә тәкъдим итүчене юллаган Казан шәһәре, Татарстан Республикасы учреждениесе, оешмасы җитәкчесе тарафыннан имзаланырга тиеш. Тәкъдим итү кәгазен тутырганда кыскартулар, аббревиатуралар куллану, төгәлсезлекләр җибәрү һәм төзәтүләр кертү рөхсәт ителми. Бүләкләү документларындагы мәгълүматларның дөреслеге өчен тәкъдим итү кәгазен рәсмиләштерүче һәм имзалаучы затлар җаваплы. Бүләкләүгә тапшырылган документларны карап тикшерү өчен вәкаләтләренә Комитет бүләкләре белән бүләкләүне координацияләү мәсьәләләре кертелгән Комитет хезмәткәрләре җаваплы.

1.6. Комитетның вәкаләтле хезмәткәрләре бүләкләүгә тәкъдим итү кәгазьләрен теркәү журналына кергән көнне теркәп, документлар керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, бүләкләүне әлеге нигезләмәнең 1.5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү өчен документлар тапшырылганнан соң 30 көн эчендә терки.

1.7. Документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бүләкләү турында яисә бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Мактау билгесе белән бүләкләү турындагы карар Комитет боерыгы белән 30 көн эчендә рәсмиләштерелә.

Бүләкләү турындагы үтенечнамәне карап тикшерү түбәндәге очракларда туктатыла:

- бүләкләү документларында булган мәгълүматларның дөрес булмавы ачыкланган очракта;

- бүләкләү документларының тулы булмаган исемлеге тапшырылган очракта.

Бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән затларның бүләкләү турындагы документлары яисә әлеге нигезләмәнең 1.4 пунктында билгеләнгән срокны бозып килгән бүләкләүгә тәкъдим итү кәгазе кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, Комитетка килгән көннән алып 30 көн эчендә инициаторга кире кайтарылырга тиеш.

Бүләкләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән затлар, яңа казанышлар булганда һәм баш тарту сәбәпләрен юкка чыгарганда, күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән бер елдан да иртәрәк булмаган вакытта кабат тапшыру хокукына ия.

1.8. Мактау билгесе һәм аңа таныклык тапшыру тантаналы шартларда Комитет рәисе яисә аның йөкләмәсе буенча башка затлар тарафыннан башкарыла.

1.9. Мактау билгесе белән бүләкләнгән зат аны күкрәкнең уң ягында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән һәм Казан шәһәре муниципаль бүләкләреннән соң тага.

1.10. Мактау билгесе белән кабат бүләкләү башкарылмый.

1.11. Мактау билгесе югалган очракта дубликат бирелми. Мактау билгесенең таныклыгы югалган очракта, Комитет рәисе карары буенча таныклык дубликаты бирелә.

1.12. Мактау билгесе белән бүләкләнгән затларны исәпкә алуны Комитет гамәлгә ашыра.

## II. Мактау билгесе тасвирламасы

2.1. Мактау билгесе медальдән һәм колодкадан тора.

Медаль җиздән эшләнгән, диаметры 32 мм, калынлыгы 2 мм булган түгәрәк формада, рельефы – медальнең аскы өлешенең үзәгеннән капма-каршы яклары буенча өскә таба юнәлтелгән ике лавр ботагы рәвешендә. Медаль аверсының аскы үзәк өлешендә «Почетный знак» («Мактау билгесе») дип

язылган очлы почмаклы тасма урнашкан. Медаль үзәгендә – Казан шәһәре Гербының рельефлы сурәте һәм язу – «ЗА ЗАСЛУГИ В РАЗВИТИИ ФИЗИЧЕСКОЙ КУЛЬТУРЫ И СПОРТА Г.КАЗАНИ». Металл төсе – алтын.

Медаль элмәк һәм божра ярдәмендә 17 мм киңлектәге, 27 мм озынлыктагы турыпочмаклыктан гыйбарәт металл колодка белән тоташтырыла. Колодка үзәгендә – күләмле хәрефләр белән «Спортивная Казань» дип язылган. Медаль һәм колодка саклагыч лак белән капланган.

Колодканың арткы ягында мактаулы билгене беркетү өчен каптырма-кадагыч бар.

2.2. Билге штамп ысулы белән композит металлдан эшләнгән. Яшел төстәге эмаль белән капланган.

2.3. Мактау билгесе өчен футляр һәм таныклык каралган.

___________________

«Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесе турындагы нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**«Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим итү**

1.Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ______________________
2. Туган көне, ае, елы ___________________________________________________
3. Туу урыны ___________________________________________________________
4. Белеме _______________________________________________________________
[кайсы уку йортын һәм ничәнче елда тәмамлаган]
5. Гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем __________________________________________
6. Яшәү урыны адресы ___________________________________________________
7. Нинди дәүләт, ведомство бүләкләре белән бүләкләнгән
_____________________________________________________________________________
8. Эш урыны, биләгән вазифасы ____________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
9. Гомуми эш стажы ______________________________________________________
10. Тармактагы эш стажы __________________________________________________
11. Әлеге коллективта эш стажы ____________________________________________
12. Хезмәт эшчәнлеге (югары уку йортларында һәм урта махсус уку йортларында укуны, хәрби хезмәтне кертеп)

| Ай һәм ел | | Оешманы күрсәтеп вазифасы | Оешманың урнашу урыны адресы |
|---|---|---|---|
| Керү | Тәмамлау (китү) | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

1 - 12 пунктларындагы мәгълүматлар хезмәт кенәгәсе мәгълүматларына туры килергә тиеш.

_____________________________________________________________________________
М.У. (вазифасы, имзасы, кадр хезмәте җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

13. Бүләкләүгә тәкъдим ителүченең конкрет казанышларын күрсәтеп, характеристика ____________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

14. _____________________________________________________ кандидатурасы

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

хезмәткәрләр коллективы җыелышы яки аның советы тарафыннан тәкъдим ителде

______________________________________________________________________

(оешманың атамасы)

______________________________________________________________________

(хезмәткәр коллективы яки аның советының җыелышы датасы, беркетмә номеры)

| | |
|---|---|
| Оешма җитәкчесе | Хезмәткәрләр коллективы җыелышының яки аның советының рәисе |
| _____________________ | _____________________ |
| (имза) | (имза) |
| _____________________ | _____________________ |
| (фамилиясе һәм инициаллары) | (фамилиясе һәм инициаллары) |
| М.У. «__» ___________ ел. | М.У. «__» ___________ ел. |

«Казан шәһәрендә физик
культураны һәм спортны үстерүдәге
казанышлары өчен» мактау билгесе
турындагы нигезләмәгә
2 номерлы кушымта (Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме тулысынча)
шәхесне раслаучы документ: _____________________ сериясе ______ номеры __________________ бирү датасы «_____» ____________________ ___________________________________________________________________,
(документны биргән орган турында мәгълүмат)

Мин 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясындагы 4 пунктының 6, 7 пунктчалары нигезендә «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты» муниципаль казна учреждениесенә җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, тапшыруны (таратуны, бирүне, файдалану өчен рөхсәтне), шәхси үзенчәлекләрен юк итүне, тыюны, бетерүне, юкка чыгаруны кертеп, автоматлаштырылган режимда, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны, атап әйткәндә, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 3 статьясында каралган гамәлләрне кылуга, минем тормыш фактлары, вакыйгалары һәм хәлләре белән бәйле белешмәләрне эшкәртүгә (теләсә нинди гамәл (операция) яисә гамәлләр операцияләр) җыелмасын кылуга) ризалыгымны бирәм.

Мине «Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгесе белән бүләкләүгә тәкъдим итү максатыннан, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә эшкәртүгә ризалык биргән шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән: фамилия, исем, атамның исеме, паспорт мәгълүматлары, туган көн, теркәлгән һәм фактта яшәү адресы, җенес, милләт, белем алу турында, бүләкләү һәм кызыксындыру чаралары, элеккеге эш урыннары, шул исәптән гомуми эш стажы турындагы мәгълүматларны 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 6 статьясы нигезендә һәркемгә ачык мәгълүмат дип санауны сорыйм.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләренә тулысынча туры китереп башкарылуы белән килешәм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымның һәм аларның әлеге ризалыкта күрсәтелгән максатлар өчен һәркемгә ачык булуының вакыты чикләнмәгән. Ул мин язма рәвештә аерым боерык чыгарганчы гамәлдә.

_______________________ (тутыру датасы)

_______________________ (гариза бирүче имзасы)